# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Фән һәм фәнни эшчәнлек турында

Бу Закон фән һәм фәнни эшчәнлек өлкәсендә икътисадый, социаль һәм башка мөнәсәбәтләрне җайга сала, фәнни һәм техник иҗат иреге гарантияләрен билгели.

### 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

<u>1 статья.</u> Фән һәм фәнни эшчәнлекне хокукый җайга салу

Фән һәм фәнни эшчәнлек Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, Татарстан Республикасының башка законнары, норматив-хокукый актлары белән, шулай ук федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары белән хокукый җайга салына.

<u>2 статья.</u> Әлеге Законда кулланылучы төп төшенчәләр

Әлеге Закон максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1. Фән - табигатъ, кеше һәм җәмгыять турында яңа белемнәр алу, туплау, аңа үзгәрешләр кертү һәм алардан максатчан файдалануның бербөтен системасы.
2. Фәнни эшчәнлек - яңа белемнәрне алуга һәм куллануга юнәлдерелгән эшчәнлек.

2.1. Фундаменталь фәнни тикшеренүләр - табигать һәм җәмгыятьнең объектив үсеш законнары хакында, табигый һәм социаль күренешләрнең закончалыклары һәм үзенчәлекләре, аларның сәбәпле-нәтиҗәле бәйләнешләре турында яңа белемнәр алуга юнәлдерелгән теоретик яки эксперименталь эшчәнлек.

2.2. Гамәли фәнни тикшеренүләр - яңа белемнәр алу максаты белән башкарыла торган һәм конкрет гамәли максатларны, бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән тикшеренүләр.

3. Фәнни нәтиҗә - яңа белемнәрдән һәм чишелешләрдән торучы һәм теләсә-нинди мәгълүмат йөртүчедә беркетелгән фәнни эшчәнлек продукты.

4. Фәнни продукция - гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән фәнни нәтиҗә, шул исәптән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсе дә.

5. Грантлар - грант бирүчеләр тарафыннан каралган шартларда конкрет фәнни тикшеренүләр өчен гражданнарның яисә юридик затларның, шул исәптән чит ил гражданнарының һәм юридик затларының кире кайтарылмый торган һәм бушлай бирелүче акчалары яисә башка средстволары.

6. Фәнни оешма - юридик зат, шулай ук төп эшчәнлеге буларак фәнни эшчәнлек белән, фәнни кадрлар әзерләү белән шөгыльләнүче һәм фәнни оешманың гамәлгә кую документлары нигезендә эш итүче фәнни хезмәткәрләрнең иҗтимагый берләшмәсе.

7. Коллектив файдалану үзәге - фәнни эшчәнлекне тормышка ашыру өчен кирәк булган фәнни, фәнни-техник һәм башка мәгълүматны, уникаль җиһазларны һәм сервисны туплый торган, килешү нигезендә финансланучы берничә фәнни оешма яисә учреждение берләшмәсе.

8. Фән өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт сәясәте - дәүләтнең фәнни эшчәнлеккә булган мөнәсәбәтен чагылдыручы, фән өлкәсендә һәм фәнни продуктларны, нәтиҗәләрне гамәлгә ашыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары эшчәнлегенең максатларын, юнәлешләрен һәм рәвешләрен билгеләүче социаль-икътисадый сәясәтнең состав өлеше.

## П бүлек. Фәнни эшчәнлек субъектлары

3 статья. Фәнни оешмалар, уртак фәнни-тикшерену үзәкләре, лабораторияләре һәм вакытлы иҗади коллективлар

1. Татарстан Республикасында законнарда каралган төрле милек рәвешләрендәге һәм төрле оештыру-хокукый рәвешләрендәге фәнни оешмалар эшли ала.

Фәнни оешмалар законнар һәм үзләренең гамәлгә кую документлары нигезендә эш итәләр.

2. Фәнни оешмалар фәнни-тикшеренү оешмаларына, югары һәнәри белем бирү мәгариф учреждениеләренең фәнни оешмаларына, тәҗрибә-конструкторлык, проект-конструкторлык, проект-технологик оешмаларга һәм фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнүче башка оешмаларга бүленә.

3. Фәнни эшчәнлекнең аерым төрләрен чикләүләр һәм лицензияләү, шулай ук фәнни оешмаларның дәүләт аккредитациясе тәртибе законнар белән билгеләнә.

4. Фәнни оешманың дәүләт аккредитациясе турында таныклык бирүдән баш тарту фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнүгә киртә була алмый.

5. Фәнни һәм башка хезмәткәрләр заказчы биргән йөкләмәне хәл итү өчен кирәкле фәнни нәтиҗәне алу максатларында шартнамә шартларында билгеле бер чорга берләшергә мөмкин (алга таба вакытлы иҗат коллективы дип аталачак). Вакытлы иҗат коллективының заказчы һәм фәнни продукцияне башка кулланучылар үзара мөнәсәбәтләре шартнамә белән законнар нигезендә җайга салына.

6. Кадрлардан һәм уникаль тәҗрибә-эксперимент җайланмаларыннан нәтиҗәле файдалану максатларында фәнни оешмалар конкрет фәнни бурычларны хәл итү өчен уртак фәнни-тикшеренү үзәкләре яисә лабораторияләр төзергә хокуклы. Күрсәтелгән үзәкләрне яисә лабораторияләрне оештыру һәм аларның эшчәнлек тәртибе фәнни оешмаларның гамәлгә кую документлары һәм законнар белән җайга салына.

7. Дәүләткә карамаган фәнни оешмалар дәүләт фәнни программалары һәм проектлары буенча фикер алышуларда, экспертиза үткәрүдә, шулай ук конкурслар нигезендә Татарстан Республикасының Республика бюджеты исәбеннән фәнни программалар, проект-

лар үтәүдә катнашырга мөмкин.

4 статья. Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмаларын төзү һәм аларның эшчәнлегенә идарә итү тәртибе

1. Татарстан Республикасының дәүләт фәнни оешмалары, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең эксперт бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсенең башка органнары тарафыннан гамәлгә куела.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсенең дәүләт фәнни учреждениеләрен гамәлгә куючы органнары:

дәүләт фәнни оешмалары уставларын раслый;

дәүләт фәнни оешмаларына бирелгән мөлкәттән нәтиҗәле файдалануны һәм аның иминлеген тикшереп тора;

законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәгә ашыра.

Дәүләт фәнни оешмаларның җитәкчеләре законнар нигезендә һәм үз уставларында каралган тәртиптә билгеләнәләр һәм сайланалар.

3. Югары квалификацияле фәнни кадрлары, уникаль экспериментал җиһазлары булган һәм фәнни казанышлары белән халыкара танылган аерым дәүләт фәнни оешмаларга билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан Республика фәнни үзәге статусы бирелергә мөмкин.

5 статья. Татарстан Республикасының дәүләт фәнни оешмаларының хокуклары

Татарстан Республикасының дәүләт фәнни оешмалары түбәндәгеләргә хокуклы:

фәнни эшчәнлекләренең төп юнәлешләрен һәм аларны гамәлгә ашыру юлларын мәстәкыйль билгеләргә;

фәнни тикшеренүләрне финанслау конкурсларында катнашырга;

фәнни хезмәтләр, даими һәм серияле басмалар нәшер итәргә, мәгълүматларның һәм белемнәрнең фәнни-техник банкларын оештырырга, конференцияләр, симпозиумнар һәм башка фәнни чаралар үткәрергә;

билгеләнгән тәртиптә гыйльми дәрәҗәләр һәм гыйльми исемнәр бирү буенча советлар оештырырга;

берләшмәләргә керергә, филиаллар, иярчен һәм уртак предприятиеләр оештырырга, контракт нигезендә фәнни эшчәнлек алып барырга;

башка фәнни оешмалар һәм предприятиеләр белән турыдан-туры бәйләнешләрне үстерергә;

гамәлгә кую документларында билгеләнгән эшчәнлекне башкару өчен гамәлгә куючылар тарафыннан беркетелүче мөлкәтне биләргә, аннан файдаланырга һәм аның белән эш итәргә. Фәнни оешмаларның мөлкәтен биләү, аннан файдалану һәм аның белән эш итү законнар белән билгеләнә;

фән өлкәсендә законнар белән тыелмаган эшкуарлык эшчәнлеген тормышка ашырырга;

эчке һәм тышкы базарларда кирәкле җиһазларны һәм материалларны сатып алырга;

интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләрен гамәлгә ашырырга;

билгеле бер вакытка белгечләр белән контрактлар төзергә һәм аларны озайтырга яисә даими эшкә алырга, шул исәптән ачык конкурслар системасы буенча да;

законнарда каралган тәртиптә төрле рәвешләрдә халыкара фәнни хезмәттәшлекне гамәлгә ашырырга.

6 статья. Татарстан Республикасының дәүләт фәнни оешмаларының бурычлары

Татарстан Республикасының дәүләт фәнни оешмалары түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:

фәнни тикшеренүләр үткәрергә, фәнни казанышларны таратырга, аларның халык хуҗалыгында кулланылуына булышырга, фәнни оешмаларның уставлары һәм фәнни-тикшеренү планнары нигезендә хуҗалык эшләрен һәм башка эшчәнлекне алып барырга;

фәнни хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрергә, аспирантура, ординатура һәм докторантура аша белгечләр әзерләүне тормышка ашырырга;

фәнни хезмәткәрләрнең хезмәт турындагы законнар белән регламентланган хокукларының һәм бурычларының үтәлешен тәэмин итәргә;

фәнни эшләнмәләрнең нәтиҗәләрен бастыруда һәм дәүләткә, юридик затларга һәм гражданнарга тапшыруда каралган тәртипне үтәргә, шулай ук дәүләт, хезмәт, коммерция серен саклау турындагы законнарны һәм башка норматив-хокукый актларны үтәргә;

фәнни, фәнни-техник, фәнни-технологик һәм дәүләтнең башка программаларын, проектларын экспертизалауда һәм гамәлгә ашыруда, шулай ук фән һәм фәнни эшчәнлек өлкәсендә дәүләт сәясәтен әзерләүдә катнашырга.

7 статья. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе

1. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Татарстан Республикасының табигать фәннәре, техник һәм иҗтимагый-гуманитар фәннәрнең иң мөһим проблемалары буенча фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләр үткәрүче һәм фәнни оешмаларның, югары һәм һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләре башкаручы фәнни тикшеренүләрне координацияләүне тәэмин итүче иң югары үзидарә фәнни оешма ул.

2. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе үз составына керүче дәүләт фәнни оешмаларының эшчәнлеген тикшереп тора.

3. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе законнар нигезендә үзенә оператив идарәгә яисә хуҗалык алып барырга беркетелгән биналарны, фәнни җиһазларны һәм башка мөлкәтне били, алардан файдалана һәм алар белән эш итә.

4. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясен финанслау Татарстан Республикасының Республика бюджеты акчалары һәм законнар белән тыелмаган башка чыганаклар исәбеннән башкарыла.

5. Фундаменталь һәм гамәли фәнни тикшеренүләрне үстерү максатларында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе һәм Татарстан Республикасының башка фәнни оешмалары Россия Фәннәр академиясе белән, чит илләрнең фәннәр академияләре белән үзара хезмәттәшлек итә, төрле федераль, халыкара һәм башка фәнни программаларда катнаша.

6. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең структурасы, аның органнарының вәкаләтләре, идарә мәсьәләләре, эшчәнлегенең юнәлешләре, аның әгъзаларын сайлау тәртибе, аларның хокуклары һәм бурычлары Татарстан Фәннәр академиясенең Уставы белән билгеләнә.

7. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе уздырылган фәнни тикшеренүләр һәм алынган фәнни нәтиҗәләр турында ел саен Татарстан Республикасы Президентына һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына хисап бирә.

8 статья. Фәнни хезмәткәр, фәнни оешма белгече һәм фәнни хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре

1. Фәнни хезмәткәр - кирәкле квалификациягә ия булучы, фәнни эшчәнлекне фәнни оешмада, вакытлы иҗат коллективында яисә мөстәкыйль рәвештә профессиональ тормышка ашыручы физик зат.

2. Фәнни хезмәткәрнең квалификациясе аттестацияләү нәтиҗәләре белән билгеләнә һәм түбәндәгеләрдә чагыла:

аның Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә, Россия Фәннәр академиясенә һәм тармаклар буенча дәүләтнең башка академияләренә хакыйкый әгъза (академик) һәм әгъза-мөхбир булып сайлануында;

аңа гыйльми дәрәҗә яисә гыйльми исем бирелүдә;

аның "фәнни хезмәткәрләр" категориясенә кертелгән хезмәт урынын биләвендә;

аңа Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе гамәлгә куйган мактаулы исемнәр, фән һәм техника өлкәсендәге казанышлары өчен дәүләт бүләкләре һәм премияләре, шулай ук чит илләрнең фәнни оешмалары бирүче бүләкләр һәм премияләр бирелүдә.

3. Урта һөнәри яисә югары һөнәри белеме булган һәм фәнни нәтиҗә алуда яисә аны гамәлгә ашыруда ярдәм итүче физик зат фәнни оешма белгече (инженер-техник хезмәткәре) була.

4. Фәнни оешмада фәнни эшчәнлек өчен тиешле шартлар тудыруны тәэмин итүче физик зат фәнни хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре була.

9 статья. Фәнни хезмәткәрләрне дәүләт аттестацияләве

Татарстан Республикасы территориясендә фәнни хезмәткәрләр квалификациясенең дәүләт аттестацияләү системасы белән тәэмин итүче һәм Россия Федерациясе белән бердәй хокукый нигезләре гамәлдә була.

10 статья. Фәнни хезмәткәрләрнең хокуклары һәм бурычлары

1. Фәнни хезмәткәр түбәндәгеләргә хокуклы:

билгеләнгән тәртиптә фәнни нәтиҗәләр авторы итеп танылырга;

авторы үзе булган фәнни продукцияне тормышка ашырудан законнар нигезендә табыш алырга;

фәнни эшчәнлеге объектив бәяләнүгә һәм үзенең иҗат өлешенә туры килерлек түләүләр, бүләкләр һәм өстенлекле ташламалар алырга;

фәнни эшчәнлек башкаруны законнар нигезендә башка төр эшчәнлек белән бергә алып барырга;

фәнни эшчәнлектә нигезле тәвәккәллеккә;

табигать, кеше һәм җәмгыять өчен хәвефле булган тикшеренүләрдә катнашудан баш тартырга;

үзенең эш урыны булган фәнни оешмаларның фәнни тикшеренүләре тематикасы буенча фикер алышуда катнашырга;

үзенең тикшеренүләрен Татарстан Республикасының Республика бюджеты, фондлар һәм башка чыганаклар исәбеннән финанслау конкурсында (шул исәптән грантлар конкурсында) катнашырга;

үзе сайлап алган фәнни проблеманы хәл итү ысулларын сайларга;

дәүләт, хезмәт яисә коммерция серен тәшкил итмәгән, фәнни нәтиҗәләр турындагы мәгълүматларны алырга;

фәнни дискуссияләрдә, конференцияләрдә, симпозиумнарда һәм башка коллектив фикер алышуларда катнашырга;

фәнни хезмәткәрләрнең иҗтимагый берләшмәләренә керергә;

халыкара фәнни һәм фәнни-техник хезмәттәшлекнең барлык рәвешләрендә (стажировкалар, командировкалар, чит илләрдә хезмәтләрне бастыру, башка рәвешләр) катнашырга.

2. Фәнни хезмәткәр түбәндәгеләрне башкарырга тиеш:

кеше хокукларын һәм ирекләрен бозмыйча, аның гомеренә һәм сәламәтлегенә, шулай ук әйләнә-тирә табигать мохитенә зыян китермичә фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнергә;

үзенә тапшырган фәнни программаларга һәм проектларга, фәнни тикшеренү нәтиҗәләренә һәм эксперименталь эшләнмәләргә объектив экспертиза ясарга.

11 статья. Дәүләт фәнни оешмаларының фәнни хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү һәм өстенлекле ташламалары

1. Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмаларының фәнни хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү гамәлдәге законнар белән билгеләнә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмаларының фәнни хезмәткәрләренә түбәндәгеләр өчен айлык өстәмә түләүләр билгеләнә:

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы исеме өчен;

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең әгъза-мөхбир исеме өчен;

фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсе өчен;

фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсе өчен;

"Татарстан Республикасының атказанган фән һәм техника эшлеклесе", "Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе", "Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе" исемнәре өчен.

Күрсәтелгән өстәмәләрне түләү тәртибе һәм аларның күләмнәре Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

3. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президиумы әгъзаларына һәм президиум аппараты хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

4. Фәнни хезмәткәрнең төп эш урынындагы вазыйфаларын башкарганда вакытлы иҗат коллективында катнашуы, шулай ук берьюлы ике урында эшләве чикләнә алмый.

5. Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмаларының фәнни оешма белән төзелгән индивидуаль шартнамә яисә контракт буенча Татарстан Республикасыннан һәм Россия Федерациясеннән читтә озак вакыт халыкара фәнни хезмәттәшлекне тормышка ашыручы фәнни хезмәткәрләре, законнарда билгеләнгән тәртиптә тиешле фондларга кертемнәр күчереп барсалар, социаль иминләштерүгә һәм пенсия белән тәэмин ителүгә хокуклы булалар.

Фәнни хезмәткәрнең чит илләрдә булган дәвере өчен пенсия исәпләгәндә хезмәт хакы күләме гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнә.

6. Дәүләт фәнни оешмаларының фәнни хезмәткәрләре түбәндәгеләргә хокуклы:

законнар нигезендә өстәмә торак мәйданына;

өстенлекле ташламалар нигезендә шифаханә-ял йортында дәвалануга һәм законнар нигезендә башка өстенлекле ташламаларга.

## Ш бүлек. Фән өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт сәясәте

**12 статья.** Фән өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтенең төп максатлары һәм принциплары

1. Фән өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтенең максаты фәнне стимуллаштырудан, дәүләт һәм җәмгыятьнең гармонияле үсеш мәнфәгатьләрендә аңа һәрьяклап ярдәм итүдән, фәннең республика җитештерүче көчләрен үстерү дәрәҗәсен билгеләүче социаль әһәмиятле эшчәнлек тармагы булуын танудан гыйбарәт.

2. Фән өлкәсендә дәүләт сәясәте түбәндәге принципларда тормышка ашырыла:

фәнни һәм техник иҗат иреге;

фәнни тикшеренүләрнең өстенлекләрен сайлауга фәнни җәмәгатьчелекне киң җәлеп итү һәм аларны конкурс нигезендә тормышка ашыру;

Татарстан Республикасының хуҗалык һәм дәүләт хезмәте өлкәсендәге галимнәрне, әйдәүче белгечләрне фәнни эшчәнлеккә җәлеп итү;

фәнни эшчәнлек субъектларын гадел булмаган конкуренциядән яклау;

финанс һәм фән ресурсларын фән һәм техника үсешенең өстенлекле юнәлешләрендә туплау;

фундаменталь тикшеренүләрне өстенлекле үстерү;

фәнни эшчәнлекне кадрларны профессиональ әзерләү белән бергә алып бару;

фән өлкәсендә икътисадый ысулларга өстенлек биреп идарә итү һәм үзидарә;

фәнни тикшеренүләр үткәрүдә контракт (шартнамә) төрләрен үстерү.

13 статья. Фән өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру

1. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты фән һәм техника үсешен фаразлау нигезендә дәүләт фәнни программаларын эшләүне тәэмин итә.

2. Фән өлкәсендә дәүләт сәясәтен башка фәнни оешмалар катнашында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең актив ярдәме белән Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнары эшлиләр һәм аны тормышка ашыралар.

3. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты фән һәм техника үсеше чараларын эшли һәм аларны тормышка ашыра, билгеләнгән тәртиптә инвестиция һәм структура сәясәте өлкәсендә, социаль-икътисадый фәнни программалар эшләү, принципиаль яңа техника һәм технологияне гамәлгә кертү өлкәсендә фәнни эшчәнлек субъектлары арасындагы бәйләнешне тәэмин итә.

4. Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнары фәнни оешмаларга фәнни программаларны һәм проектларны гамәлгә ашыруда, дәүләт фәнни оешмаларына һәм уку йортларына фәнни хезмәткәрләр әзерләүдә һәм аларның белгечлекләрен күтәрүдә ярдәм итә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, кызыксынучы оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләре инициативасы белән, бәйсез экспертлар һәм эксперт комиссияләре катнашында фәнни программаларга һәм проектларга экспертиза үткәрергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты яки аның кушуы буенча кызыксынучы оешмалар фәннең иң яңа казанышларын файдалана торган производстволарның һәм объектларның хәвефсезлегенә, экологик чисталыгына, социаль-икътисадый әһәмиятенә кагылышлы экспертиза нәтиҗәләре турында халыкка алдан ук хәбәр итәләр.

14 статья. Фәнне һәм фәнни эшчәнлекне финанслау

1. Фәнне һәм фәнни эшчәнлекне финанслау түбәндәгеләр исәбеннән башкарыла:

Федераль бюджет акчаларыннан;

Татарстан Республикасының Республика бюджеты һәм җирле бюджетлар акчаларыннан;

бюджеттан тыш фондлар һәм законнар белән рөхсәт ителгән башка чыганаклар исәбеннән.

2. Фәнне һәм фәнни эшчәнлекне Татарстан Республикасының Республика бюджеты акчаларыннан финанслау күләме, Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль үсеше буенча озак вакытлы программаларын гамәлгә ашыру чыгымнарын исәпкә алып, чираттагы елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турындагы законында билгеләнә.

3. Татарстан Республикасының Республика бюджеты акчалары исәбеннән беренче чиратта фундаменталь фәнни тикшеренүләр, шулай ук Татарстан Республикасының гуманитар, фәнни-техник һәм технологик максатчыл программалары кысаларында эшләнүче проектлар финанслана. Фәнни - тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык эшләрен башкаруга дәүләт заказы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслаган нигезләмә нигезендә конкурс буенча билгеләнә.

4. Яңа төр продукцияләрне үзләштерү буенча фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләрен һәм гамәлләрен финанслау Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре буенча республика фонды, шулай ук Татарстан Республикасы законнары нигезендә бүтән фондлар исәбеннән тормышка ашырыла.

5. Фәнни эшчәнлек үзебезнең һәм чит илләрнең юридик һәм физик затлары, шулай ук чит дәүләтләр һәм халыкара оешмалар тарафыннан бүлеп бирелүче кире кайтарылмый торган акчалары һәм башка средстволар белән грантлар рәвешендә финансланырга мөмкин.

Грантлар фәнни оешмаларга, уку йортларына, вакытлы иҗат коллективларына һәм аерым фәнни хезмәткәрләргә бирелә.

Грантлар рәвешендә средство алучылар алардан билгеләнгән тәртиптә һәм грантларда күрсәтелгән шартлар нигезендә файдаланалар.

6. Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре буенча республика фондыннан кирә торган акчалар түбәндәгеләр өчен файдаланыла:

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе үткәрә һәм координацияли торган фәнни тикшеренүләрне финанслау;

республиканың максатчыл фәнни программаларын һәм проектларын гамәлгә ашыру;

югары технологияле һәм экологик яктан чиста производстволар булдыру һәм үзләштерү;

фән, техника һәм технологиянең перспектив һәм яңа юнәлешләре буенча фәнни хезмәткәрләр әзерләү, шул исәптән аларны чит илләрдәге фәнни үзәкләрдә әзерләү һәм яңадан әзерләү программаларын гамәлгә ашыру.

7. Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органнары, гражданнар һәм юридик затлар, шул исәптән чит илнекеләр дә ихтыярый нигездә фәнне һәм фәнни хезмәткәрләрне финанслау һәм аларга ярдәм итү өчен фондлар төзи алалар.

15 статья. Татарстан Республикасында фәнне һәм фәнни эшчәнлекне икътисадый кызыксындыру

Фәнни оешмаларга салымнар һәм бюджетларга, бюджеттан тыш фондларга мәҗбүри түләүләр буенча өстенлекле ташламалар законнар белән билгеләнә.

16 статья. Фәннең матди-техник базасына дәүләт ярдәме

Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары Татарстан Республикасының дәүләт фәнни оешмаларына, аларның матди-техник базаларын үстерү һәм нигыту уникаль фәнни җиһазлар сатып алу, аларга сервис хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыруда, шулай ук күмәк файдалану үзәкләре оештыруда ярдәм итәләр.

17 статья. Фәнни эшчәнлекне мәгълүмати тәэмин итү

1. Фәнни оешмалар һәм фәнни хезмәткәрләр мәгълүматлар алмашырга хокуклы, моңа дәүләт, хезмәт һәм коммерция серләренә караган белешмәләр булган мәгълүмат керми.

2. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты фән өлкәсендә фәнни мәгълүмат җыюны, дәүләт теркәвен, аналитик эшкәр-

туне, саклауны һәм кулланучыларга җиткерүне гамәлгә ашыручы республика мәгълүмат фондлары һәм системалары төзүне тәэмин итә, китапханә эшенә һәм фәнни продукцияне бастыруга, чит илләрдә нәшер ителгән фәнни журналларны, китапларны һәм басма продукцияне сатып алырга ярдәм итә, фәнни хезмәткәрләргә һәм оешмаларга дәүләтара һәм халыкара мәгълүмат фондларына һәм челтәрләренә үтеп керүне гарантияли.

3. Үзендә фәнни мәгълүмат белешмәләренең банклары һәм базалары булган дәүләт фәнни оешмасы бетерелгән очракта, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләнгән тәртиптә аларның саклануын һәм тиешле хокук дәвамчысына тапшырылуын тәэмин итә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1998 елның 18 июне
N 1661